**Мөслим гимназиясе укучылары газетасы**

# ТЫЛСЫМ+

№2 (24) Ноябрь, 2017 нче ел

## Бу санда:

*Гимназия сулышы* 1

*Укучыларыбыз туган тел сагында* 2

*Мөслимемне милли итеп күрәсем килә...* 3

*Йөрәгемне былбыл чакты...* 4




***Хөрмәтле әниләребез!***

***Чын йөрәктән сезне барыгызны да Халыкара Әниләр көне белән котлыйбыз. Сезнең ягымлы йөзләрегездә һәрвакыт шатлык балкысын, сау-сәламәт булыгыз! Без сезне бик яратабыз!***

***Гимназия укучылары***

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### “МИНЕМ ИҢ ЯХШЫ ДӘРЕСЕМ” БӨТЕНРОССИЯ ПЕДАГОГИК ОСТАЛЫК БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕСЕ

18 нче ноябрьдә Казан шәһәре Яңа Савин районы аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелүче №179 мәктәбе базасында “Минем иң яхшы дәресем” (”Мой лучший урок”) Бөтенроссия педагогик осталык конкурсының региональ этабы узды. Гимназиянең башлангыч сыйныфлар укытучысы Гомәрова Алсу Рауил кызы нәтиҗәле чыгыш ясады - 2 нче дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде.





### УКУЧЫБЫЗ - ТОЛСТОЙ УКУЛАРЫ ҖИҢҮЧЕСЕ

2 нче ноябрьдә КФУда Лев Толстой исемендәге Бөтенроссия фәнни конференциясе узды. Мөслим гимназиясенең 9а сыйныфы укучысы Сәфәргалина Ильвина Рим кызы фәнни җитәкче Авзалова Зилә Зөфәр кызы белән берлектә, “Татар теле: тарих һәм заман” юнәлешендә эзләнү-тикшеренү эше белән шөгыльләнеп, “Ф.Садриев әсәрләрендә фразеологик әйтелмәләр” темасына уңышлы чыгыш ясады. Сәфәргалина Ильвина 3 нче дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде.

### КӘРИМ ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНА СӘЯХӘТ

Көзге каникул көннәрендә гимназиянең дәрестән тыш эшчәнлегендә аеруча актив булган бер төркем укучылар Казан шәһәрендә экскурсиядә булдылар. Шәһәрнең тарихи-истәлекле урыннарында булып, К.Тинчурин театрында “Сүнгән йолдызлар” спектаклен тамаша кылып кайттылар. Сәяхәтне Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, район мәгариф идарәсе, ата-аналар комитеты оештырды.





### КУЛЛАНЫЛГАН КӘГАЗЬЛӘРГӘ – ИКЕНЧЕ ТОРМЫШ

Ноябрь ае макулатура җыю айлыгы буларак игълан ителде. Бу уку елында кулланылган кәгазьне җыю шартлары үзгәрде. Ел дәвамында иң күп күләмдә макулатура җыючы сыйныф спонсор бүләге – принтерга ия булачак. Узган ел нәтиҗәләре буенча, Мөслим гимназиясе “Иң актив мәктәп” буларак, мондый бүләккә ия булды. Алдагы бүләк кемнеке булыр? Анысын вакыт күрсәтер.




ГРАМОТА
НАГРАЖДАЕТСЯ
МБОУ
«Муслюмовская гимназия»
директор –
Мирзаянов Азат Фаритович
победитель экологической акции:
«БУМАГЕ – ВТОРУЮ ЖИЗНЬ»
-2016-2017 учебный год –
в номинации
«Лучшая школа по общему количеству сданной макулатуры»
С Уважением,
Директор ГК «ЭКОЛАБ» / А.В. Уросов/
г.Набережные Челны
2017 год

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ТУГАН ТЕЛ САГЫНДА

### МИН - ТАТАР КЫЗЫ!

Күпме мәгънә, күпме горурлану хисе салынган бу юлга! Горурланырлык та шул. Тукае, Сәйдәше, Туфаны, Сөембикәсе булган горур милләт кызы бит мин.

Әйе, моңлы Тукайлары, батыр Җәлилләре, мәхәббәтле Кол Галиләре... һәм, ниһаять, тимер кебек көчле ихтыярлы Минтимерләре бар милләтемнең. Алар бит - татарның йөзек кашлары. Шундый көчне каян алган, ничек моңлы булган, батыр булганнар? Ул көч - халыкта, туган җирдә, туган телдә. Мин үземнең җырлы-моңлы туган телемә, горур милләтемә мөкиббән. Татар телендә сөйләшүем, Татарстан җирендә яшәвем белән бик бәхетле мин.

Татар халкы яшәмәгән урын бармы икән Җир шарында?! Кайда гына яшәсә дә, татар кешесенә эш сөючәнлек, кунакчыллык, гаделлек, пөхтәлек кебек сыйфатлар хас. Чит илләрдә яшәүче татарларда бу сыйфатлар бигрәк тә ачык сизелә. Алар һәрвакыт татарларның үзәге булган Татарстанны сагыналар, телләрен онытмыйлар, динне, гореф-гадәтләрне, милли йолаларны саклыйлар, рухи яктан көчле булырга тырышалар, милли бәйрәмнәрне бергәләп үткәрәләр.

Татар халкының милли бәйрәме - Сабантуй гына да ни тора! Ул инде күптән Татарстан чикләрен үтеп чыкты. Башка милләт халыклары да рәхәтләнеп Сабан туен бәйрәм итәләр, аралашалар. Ул чын-чынлап дуслык бәйрәменә әверелде.

Шулай да бүгенге хәр, ирекле тормыш җиңел генә бирелмәгән. Тарихка әйләнеп кайтсак, күпме михнәт күргән безнең халык.

...1552 нче елда борынгы бабаларыбыз үз дәүләтен югалтуга дучар ителгән, азатлык өчен көрәштә күпмесе шәһит киткән, Сөембикә-ханбикә кулга алынган. Буйсынмаган, халкын, динен сатарга теләмәве, онытмавы өчен Явыз Иван төрле җәзалар биргән: яратмаган кеше белән яшәргә мәҗбүр иткән, сөекле улыннан аерган, рухи яктан Сөембикәне сындырырга тырышкан. Татар халкының горурлыгын үзендә чагылдыручы мәһабәт Сөембикә манарасы бүген шуның тарихи символы булып тора. Тигезсез көрәштә шәһит киткәннәрнең каны тамган җирдә күтәрелгән Кол Шәриф мәчете, бүгенге буынга үткәннәрне онытмаска өндәп, азан тавышын яңгырата.

Татар милләтенең тугрылык символы булып, Гаяз Исхакыйның Зөләйхасы тора. Үзенең диненә, теленә, милләтенә гомере буена тугрылык саклаучы Зөләйха образы күпме татар халкының прототибы ул. Күпме ихтыяр көче, күпме көчле рух кирәк булган! Алар милләтнең йөз аклыгын саклаганнар, шушы асыл сыйфатларны киләчәк буынга тапшырыр өчен күпме михнәт чиккәннәр.

Тарихны хаклы рәвештә халык хәтере, диләр. Бүгенге буын үзенең үткәнен белергә, хөрмәт итәргә һәм аны киләчәк буынга тапшы-рырга тиеш. "Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк", диелә. Без үткән буын каршында бурычлы. Алар тапшыр-ган эстафетаны без түкми-чәчми киләчәк буынга тапшырырга тиеш.

Мин татар халкының башка милләт халкына игелек кенә кылып яшәве, тигез хокуклар биреп, үз кочагында яшәтүе, диннәрен, йолаларын хөрмәт итүе белән чиксез горурланам. Милләтемнең киләчәгенә зур өметләр баглыйм.

*Татарстан дигән Ватаным бар,*
*Татар дигән халкым бар минем.*
*Узганнардан түгел, мин халкыма*
*Киләчәктән урын барлыймын.*

***Язилә Исмәгыйлова,***
***11 нче а сыйныфы укучысы***

---

### МИЛЛӘТЕМ - КИЛӘЧӘГЕМ

*(Татлы төш)*

- Искәндәр, нигә син кабат татар теленнән өй эшен эшләмәдең? - дип башлады укытучы дәресне.

- Кирәкми миңа татар теле, - диде Искәндәр.

- Ничек инде үз туган телең кирәкми?!..

Сорау җавапсыз калды. Шул ук кич Искәндәр янә татар теленнән өй эшен эшләмичә йокларга ятты.

...Менә ул таныш сукмагыннан мәктәбенә таба атлый. Әмма бүген бар нәрсә дә башкачарак кебек. Бар җирдә матурлык, яктылык хөкем сөрә. Салмак кына Сәйдәш көйләре яңгырый, кешеләр бер-берсе белән елмаеп саф татар телендә исәнләшәләр, хәл-әхвәлләрен сорашалар. Кичә генә аллы-гөлле русча, инглизчә язылган реклама такталарында татар телендә игъланнар, милли бизәкләребез урын алган. Алар арасында "Европада татар көннәре", "Татар интернеты", "Татарлар дөнья мәйданында" һәм башка шундый язмалар күзгә чалына.



Мәктәп алдында Искәндәр татар теле укытучысы Эльмира Василовнаны очратты.

- Хәерле көн, Искәндәр! – дип дәште Эльмира Василовна.

- Исәнмесез! Төн чыкканчы нәрсә булды бу җиһанга? Тирә-якта саф татар телендә аралашалар, бар җирдә милләтпәрвәрлек сизелә, кичә әле бу сирәк күренеш иде, - диде Искәндәр, хәйран калып.

- Без синең белән бүген киләчәктә! Могҗизалар моның белән генә бетми әле. Әйдә, башка җирләргә дә сәяхәт кылыйк,- диде Эльмира Василовна. Искәндәр берсүзсез ризалашты.

Бер көн эчендә Искәндәр укытучысы белән шактый җирләрдә булды: музейлар, китапханә, уку йортларында...

Музейларда ул үзенең милләтенең тарихы, гореф-гадәтләре, бай мирасы белән танышты. Югары уку йортларында чит илдән килгән студентларның (алар арасында Америкадан, Франциядән, Африкадан килгәннәре бар иде) тырышып-тырышып татар телен өйрәнүләре бик гаҗәпләндерде. "Минем милләтемне чит илләрдә дә беләләр икән!" – дигән горурлык хисе белән алды аны.

Китапханәләрдә ул татар милләтенең күренекле язучылары, шагыйрьләре, зыялы шәхесләре турында күп мәгълүмат алды. Бер уңайдан телевидение бинасына да кереп чыкты. "Милләтем – киләчә-гем!" тапшыруында Искәндәр үзе дә катнашты.

...Татлы төшеннән Искәндәр сискәнеп уянып китте. Тиз генә торып, татар теле китабын алды, өй эшен эшләде. Моңа кадәр туган теленә күрсәткән битарафлыгы өчен гарьләнде.


"Әнә бит, милләтнең киләчәге нинди якты, өметле!" – дип уйлады ул. - Мин дә бит шул өметле милләтнең бер баласы. Димәк, татар милләтенең якты киләчәгендә минем дә өлешем булырга тиеш!"

***Миләүшә Зиязова,***
***10 нчы б сыйныфы укучысы***

# МӨСЛИМЕМНЕ МИЛЛИ ИТЕП КҮРӘСЕМ КИЛӘ...

Шушы яктан, шушы туфрактан без... Дөньяда һәр кешенең үзенә кадерле җире бар. Ул - аның туган җире, туган төбәге.

Минем туган ягым – Мөслим. Үз җиремдә миңа һәр нәрсә матур, кадерле, йөрәгемә якын. Мөслимебез табигатьнең иң матур җиренә урнашкан: Иске авыл таулары ышыгына утырган авылым янынnan бөргаланып-сыргаланып Ык елгасы ага. Әрәмәләрдә бөдрә таллар, ак күбектәй ап-ак чәчәккә күмелгән шомыртлар, күз явын алырлык кып-кызыл балан, камырлык, агачларны чорнап үскән колмак, шәмәхә күзле бөрлегәннәр, болыннарда, тау битләрендә бармак башы хәтле җиләкләр тагын кайда бар икән?!



Бай тарихы, үткән мирасы, бүгенгесе һәм киләчәге белән күпләргә үрнәк булырлык авыл ул Мөслим.

Безнең җирлек - дөньяга танылган шәхесләр бүләк иткән төбәк ул. Берничәсен генә телгә алу да җитә. Прозаиклар Фоат Садриев, Факил Сафин, Флүс Латыйфи, шагыйрьләр Зөлфәт, Наис Гамбәр, Харрас Әюп, Шәмсия Җиһангирова, галимнәребез Марсель Бакиров, Дания Заһидуллина, җырчы Зифа Басыйрова, актерлар Наил Әюпов, Зөфәр Харисов исемнәре генә дә ни тора? Телебез, милләтебез, әдәбиятыбыз, мәдәниятебез, фәнебез сагында торучы әлеге затларның исемлеген дәвам итәрдәй зыялы шәхесләр бүгенге мохиттә тәрбияләнә. Ана телен - татар телебезне яратып өйрәнәбез, рәхәтләнеп үз телебездә аралашабыз, барлык чараларны татар телендә оештырабыз. Телебезне өйрәнүнең мөһимлеген бөтен нечкәлеге белән аңлыйбыз.

Мөслимдә миллилекне югалтмау мөһимлеген тирән аңлап эш итәләр.

Авыл эчендәге баннерларда туган җиребезнең кадере, милләтебезне, телебезне, Мөслимлеләр буларак үз йөзебезне саклау турында эчтәлекле фикерләр язылган. Болар безгә, яшь мөслимлеләргә, өлкәннәрдән килгән мирасны саклаpга кирәклеге турында искәртеп торадыр кебек.

Мин – Мөслим гимназиясенең чыгарылыш сыйныф укучысы. Чагыштырмача яшь саналса да, Мөслимебездә гимназиянең үз йөзе, үз урыны, хәтта дәрәҗәсе бар. Татар мәктәпләренең абруен саклап калып, 500 ләп балага белем бирә. Зыялы татар яшьләре тәрбияләүче бер учак ул. Фән олимпиадалары, интеллектуаль бәйге, иҗади конкурслар, спорт бәйгеләре ярышларында Мөслим данын яклап чыгышлар ясыйбыз. Безнең арада Бөтенроссия “Илһам” яшь язучылар бәйгесе җиңүчеләре, Халыкара “Президент ярышлары” спорт уеннары җиңүчеләре, милли көрәш буенча Татарстан Республикасы, билбау көрәше буенча Россия чемпионы бар. Гимназиянең укучылар үзидарәсе бик әһәмиятле эш башкара. Безнең ике телдә чыгып килүче үз газетабыз бар.



Мөслимнең милли йөзе булырга тиеш. Авылыбызның йөзек кашы булырдай “Җәмигъ мәчете”, татар шәхесләренең исемнәрен йөртүче урамнар, “Туган як” музее, “Курай” ял паркы, “Тукай скверы”, “Кояшлы Ык” ял итү зонасы, үзәк урамдагы “Мөслим йөрәге” җәяүлеләр аллеясы, “Җиңү паркы”, “Батырлар стеласы”, татар телендә чыга торган “Авыл утлары” газетасы - болар аз түгел, билгеле. Ә һәр атнада зәңгәр экраннарга чыгып, Мөслимебез яшәешен яктырта торган “Мөслим телевидениесе” тапшырулары. Зифа Басыйрова исемендәге мәдәният сарае, “Мизгел” яшьләр үзәгендә оештырылган әхлак, әдәп, тәрбия чараларын күңелләргә иңдерүче чаралар үзләре генә дә ни тора?!

Булганына шөкер итеп, яшәешебезне тагын да ямьләндерү, мәгънәлерәк итү турында уйлыйсы бар. Мөслимдә зур һәм бай тәҗрибәле “Милли ашлар йорты” булсын иде. Бу бит милли йөзебезне, татар кунакчыллыгын күрсәтү өчен иң кирәкле нәрсә.

Мөслим төбәге элек-электән үзенең сабантуй батырлары белән дан тоткан. Спорт мастерлары Рим Синәкәев, Артур Сафин, атаклы көрәшчеләр Гаяз Авзалов, Расил Фаттахов, Георгий Пискунов, Илнар Сәетгалиев турында горурланып сөйлибез. Милли көрәшне спорт төре буларак үз иткән яшьләр спорт залларында шөгыльләнә. Ә нигә татар милли көрәшен үстерү, милли уеннар өчен тиешле югарылыктагы аерым бина булдырмаска?

Белдерүләр, элмә такталар, оешма, кибет исемнәре татарча булуы күңелне сөендерә. Милли архитектураны исәпкә алып төзелгән яки яңартылган бинаgar, парк, скверлар, балалар мәйданчыклары шат авазлардан яңгырап торсын иде.

> ***“Һәрвакытта ислам динебезне вә телебезне өйрәнергә теләячәкбез һәм телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәглыдыр. Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз”.***
>
> ***Садри Максуди***

Гасырлар буена сыналган, әби-бабаларыбыздан килгән бик акыллы сүзләр бар. Берсендә болай дип язылган: “Әгәр дә нәрсәдер эшләргә телисең икән - вакыттан алда бар, нәрсәдер эшләп өлгерергә телисең икән - вакыт белән бергә бар”. Күңеле һәм эше белән татар телебезне, гореф-гадәтләребезне, милләтебезне саклау һәм үстерү, мәдәниятебезне тиешле югарылыкка күтәрү юнәлешендә армый-талмый хезмәт итүне алга сөрүче һәр кешегә, афәрин, дияргә язсын!



“Булган кешенең кулында бер уч туфрак та алтынга әйләнер” - ди халык мәкале. Яшьтәшләрем арасында уйлаганнарын тормышка ашыра алучы шәхесләр үсеен телим. Матур эшләребез белән Мөслимебез тарихына үз исемнәребезне дә яза алсак иде.

***Динара Салихова,***
***11 нче а сыйныфы укучысы***

## ЙӨРӘГЕМНЕ БЫЛБЫЛ ЧАКТЫ...



**Таң җиледәй әкрен генә назлап,
Бүген җанны шигырь уятты.**

### Кыш

Иртән торсам, тәрәзәне
Бизәп киткән Кыш Бабай.
Урамны да күрә алмыйм,
Шаярма инде алай!
Мәктәпкә барыр алдыннан
Күз салам тәрәзәгә.
Кыш буе шулай шаярсаң,
Ничек сиңа түзәргә!?

***Мингазова Ралина,
4 нче б сыйныфы укучысы***

### Пескәем

Тегеп куйдым бер күлмәк,
Елтыр-елтыр килә ул!
Минем матур күлмәгем
Бик ошатты пескәем.
Бигрәк матур күлмәк, дип,
Минем өчен шатланып,
Елтыратып күзләрен,
Карап тора сокланып.

***Мәрданова Камилә,
4 нче б сыйныфы укучысы***

### Бәхет агачы

Бәхет агачы ясадык
Әнием белән бергә.
Тәңкә саен теләкләр
Теләдек һәммәбез дә.

Иң кирәге – сәламәтлек,
Сәламәт булсын һәркем.
Авырмыйм, чирләмим, дип
Зарядка ясыйм һәр көн.

Әйтерсең лә, чын агач,
Исем китте ясагач.
Яфраклары - чын бәрхет
Теләп торсын ул бәхет.

***Илнара Әюпова,
3 нче а сыйныфы укучысы***

### Тынычлык телим

Зәңгәр күктә – ак болытлар,
Уйный кояш нурлары.
Алтын бодай башаклары
Дулкынлата кырларны.

Сокланабыз гүзәллеккә,
Барыбыз бер фикердә:
Тилмермәсен кеше ачка,
Сугыш булмасын җирдә.

Кара кайгы – сугыш җиле
Кермәсен илебезгә.
Аяк чалмасын бомбалар
Киләчәк көнебезгә!

***********

### Күк йөзендә алтын урак

Туган җирем, сабый бала кебек,
Изрәп йоклый, татлы төш күреп.
Төн уртасы.
Тик тынгысыз әтәч
Сөрән салды, төшне бүлдереп.

Зәңгәр күк йөзендә алтын урак
Гизеп йөри йолдыз басуын...
Төн пәрдәсен ачты алсу нурлар,
Хәбәр итеп таңның атуын.

***Солтанова Алия,
6 нчы б сыйныфы укучысы***

## ГАИЛӘМ – МИНЕМ ТЕРӘГЕМ



Һәркемнең тормышы туган йорттан, гаиләдән башлана. Гаилә ул - сине яклый, саклый торган бер оя. Бу ояда кеше үзен бәхетле, тыныч күңелле итеп тоя.

Тигез гаиләдә әти-әнием, сеңлем, туганнарым янәшәсендә яшәгәнгә, мин үземне бик бәхетле бала дип саныйм.

Мин - әти-әниемнең көтеп алган беренче балалары. Минем беренче атлап китүемне, сөйләшә башлавымны өзелеп көткәннәр алар. Чәчләремне үреп, матур итеп киендереп, әтием кочле кулларына күтәреп, мине балалар бакчасына йөрткән.

Ә беренче сыйныфка мине бөтен гаиләбез, туганнарыбыз белән озаттылар. Һәрберсе мине укырга керүем белән котлады, бүләкләр бирде. Мин бөтен көчемне биреп, әти-әниемнең ярдәмен тоеп, бик тырышып укыйм. Кемдер авыр сүз әйтеп рәнҗетсә дә, борчу мәшәкатьләрең булса да, иң элек әниеңә таянасың, эч серләреңне аңа сөйлисең.

Хәзер инде мин дүртенче сыйныфта укыйм. Әти-әнием, әби-ем-бабам тырыш, булдыклы кешеләр булганга күрә, минем дә көчле, уңган кеше буласым килә! Хыялларымны тормышка ашырырга миңа, әлбәттә инде, иң газиз кешеләрем - әти-әнием булыша.

Дөньядагы һәр баланың да минем кебек бәхетле гаиләдә яшәвен телим!

***Сөмбел Галиева,
4 нче б сыйныфы укучысы***

**ТЫЛСЫМ+**

Ноябрь, 2017 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина
Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Салихова Динара
Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:**
Гилемов Азат
Шарифуллин Заһир
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym